| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 24.05.2024 г. Казань № 402/2024

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 31.08.2023 №565/2023 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын актуальләштерү максатларында
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 31.08.2023 № 565/2023 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның икенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, Дәүләт комитеты) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда, башка федераль законнарда коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларның үтәлешен (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу) тәэмин итүдә;»;

3.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга комачаулаучы, аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итүе.»;

3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән белдерүләр коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи зат тарафыннан карала, ул белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерли.»;

3.4.2 пунктында «3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «3.1 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.3 пунктта:

«а» пунктчасында 3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен 3.1 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә белдерүләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18, 3.18.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планга кертелгән) утырышында карала.»;

3.8 пунктта «3.1 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «3.1 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.1 пунктның «а» пунктчасында «3.1 пунктның» б « пунктчасы белән» сүзләрен «3.1 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 3.18.1 пункт белән тулыландырырга:

«3.18.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а»-»е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча, моңа нигезләр булган

очракта, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11-3.15.1, 3.17-3.18, 3.18.1 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетның мәгълүмати-техник хезмәт күрсәтү бүлегенә әлеге боерыкны Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина